Мишәр җырлары Казанда кирәк

Октябрь аенда безнең районда Татарстаннан килгән фәнни—тикшеренү экспедиция хезмәт итте. Бу экспедициянең төп максаты: безнең җирдәге татар—мишәрләрнең халык авыз иҗатын өйрәнү һәм җыю булды. Н.Г. Җиганов исемендәге Казан дәүләт консерваториянең фольклор—этнографик кабинеты вәкилләре — экспедициянең рәисе Лилиә Харис кызы Җиганшина һәм безнең якташыбыз, консерваториянең студенткасы Наталья Бабина. Натальяның әнисе—мишәр, Кочкурово төбәгенең татар авылында туган, шуңа күрә бу кызга мишәр татар мәдәни гореф—гадәтләре дә якын.

Бу әмәлне оештырырга ярдәм кылучылар, Ләмберә районының татар мәдәни үзәгенең директоры Әльфиә Асым кызы Максимова һәм үзәкнең методисты Алсу Сюбаева, районыбызның мәдәни йортның җитәкчесе Виктор Петр улы Кирсанов казан белгечләре белән мишәр фольклорын башкаручыларының очрашуын оештырдылар. Безнең иң якты, көчле җырчылар казан кунаклары өчен яңгыравыклы тавышлары белән бик күп колоритлы, үзенчәлекле мишәр җырларын җырладылар. Аларның арасында: Нуриә Садыйк кызы Абдрашитова Чирмеш авылыннан, Равилә Садыйк кызы Аймурзанова Ләмберә авылыннан, «Дуслык» фольклор төркеменең башка җырчылары Рәшидә Али кызы Ишкаеваның җитәкчелегендә күңелләрне күтәреп, искиткеч тавышлары белән бик матур борынгы бәетләр көйләделәр. Безнең сәләтле өлкән апаларыбыздан Казаннан килгән кунаклар йөздән артык җыр язып алдылар. Бу иске, әби—бабаларыбыздан калган, музыкаль әсәрләре арасында — күптәнге мөнәҗәтләр, бәетләр, озын көйлә җырлар, такмаклар. «Әбдельмән—купигә», «Мәхәббәт бәете», «Сатучылар», «Казаннарда тайлар асырыйлар», «Киндерләр җәйдем», «Айшюк», «Сәйфелмәлүк», туй җырлары һәм башкалар. Сагышлы, моңлы иске лирик җырларын татар халык җыр һәм бию «Умырзая» ансамбленең баш җырчысы Альфия Асым кызы Максимова җырлады. Аның башкаруында да казан тикшеренүчеләре күп лирик бәетләр һәм борынгы җырлар тыңладылар һәм язып алдылар. Болар арасында, мәсәлән, җан әрнеткеч «Өстәл өстендә ике савыт» һәм «Кыз бала» дигән озын көйле җырлар. Әльфиә Асым кызы бу борынгы көйләрне әтисе—әнисеннән өйрәнеп калды. Һәм үзе шулай безгә әйтте: «Элкеге заманаларда, сугышка кадәр, тагын да иске вакытларда, күбесе җырларны кунакларда өстәл артында ирләр җырлаганнар. Хатын—кызлар тыңлап кына торганнар. Шуңа күрә, иске җырларның сюжет, мәгънәләрен күзәтеп алсак, аларның ир исеменнән җырлавын аңларга мөмкин.

Сонрак «Умырзая» ансамбленең әгъзасы Альфиә Чуракова, солисткасы Альфия Максимова һәм җитәкчесе Фаилә Равилова кунаклар өчен «Әй, Ләмберәм!» дигән җырны тәкъдим иттеләр. Үз җиребездә туган, үз авторларыбыз белән язылган җыр фольклор тикшеренүчеләрне бик кызыксындырды һәм күңелләрен тутырды.

Экспедициянең икенче көнендә җыр туплаучылар Татар Севәрбе авылына да җиттеләр. Андагы «Зөләйха» исемле фольклор төркеме белән танышыр өчен, алар бу төркемнең җитәкчесе Каюм Гани улы Апарин белән һәм «Зөләйханың» солисткасы Галиә Хәсән кызы Алькаева белән таныштылар. Галиә апаның өй бусагасын атлагач, казанчылар чын кунаклар булдылар. Кунакчыл, кече күңелле хуҗабикә Галиә апа иптәше Җәфәр Зәкир улы белән, бу кунакларны иртә белән, анықланып, табынны каплап, көткән. Алардан да Лилиә Харис кызы Наталья белән күп җырлар язып алганнар. Һәм тагын да җыр капчыкларын борынгы бәетләр һәм Севәрби такмаклары белән тутырганнар.

Бу фольклор экспедициянең ахырында, китәр алдыннан, казан кунаклары безнең оештыручыларга бик зур рәхмәтләр әйттеләр һәм үзләренең якты тәэсирләре белән бүлештеләр.

— Моңдый, бәя биреп бетергесез, борынгы халык авыз иҗатыгызны саклый белгәнгә — сезгә зур хөрмәт һәм бик күп рәхмәтләр. Сезнең мишәр татарлары белән тулган Ләмберә районыгыз үзенең күпмиллэтле, үзенчәлекле татар мәдәни хәзинәсе белән, башка өлкәләрнең татар районнарыннан аерылып тора. Ләмберә районының авыллары икән шундый җыр—моңга, иске гореф—гадәтләргә, йолаларга бай, монда шундый күп башкаларга охшамаган, күчереп алынмаган җыр фольклоры җыелган! Һәрбер авылда җырларның үз сүзләре, үз тиңе булмаган көе, үз әйтелеше — ләкин бөтенесендә — бер моң! Бу бай хәзинә үлгән йөк кебек түгел, ә тере җан булып, җырлана һәм буыннан буынга күчә. Шуларга йөрәкләр киңәеп тора. Иң зур рәхмәт — сезнең «Дуслык» төркемеңез өлкәшәренә. Аларның тырышлыгына, җыр сөюләренә һәм моңдый матур башкаруларына күрә, татар—мишәр җырлары онытылмый, буыннарда саклана һәм яшь сәләтле иясләренә тапшырыла.

Әниләр көненә багышлана

Гасырлардан килә торган мирас

Черемиш авылының мәдәният йортында авылның төп мәктәбенең ата—аналар комитеты рәисе Ерзина Наилә Нәим кызы һәм авыл китапханәсенең җитәкчесе Солдатова Лариса Барий кызы җитәкчелегендә «Әниләр бәйрәме» көненә багышлаган музыкаль кичә үткәрелде. Биредә белем учагының укучылары аналарына булган мәхәббәт хисләрен сәхнә номерлары аша тапшырды. Һәр чыгыш аерым бер сөю ялкыны, аерым бер әйтеп бетерәлмәслек наз белән сугарылган иде. Курмакаева Диана белән Алукаева Динараның ике телдә әни кешеләргә тәкъдим ителгән җырлары, аналарның төрле милләт, төрле дин халкы өчен дә газиз икәнлеген дәлилләде. Хисләрне белдерү өчен кайчак сүзләрнең булуы да мөһим түгел. Алина Ерзина Курмакаева Карина белән башкарган моңлы көйдән соң аналарның алсу йөзләрендәге яшь тамчылары моңа ачык дәлил булып тора. Кичәгә күп балалы әниләр чакырылды: Солдатовна Лариса, Конькова Наилә, Карабанова Альмира, Карабанова Гүзәл, Аббясова Гульнара, Альмяшева Рәшидә, Прянкова Наилә, Алукаева Лариса һәм Сюбаева Эльвира (ялгыз ул тәрбияли).

Кичә барышында «Ягез, әниләр!» конкурсы үткәрелде. Биредә кичәгә чакырылган аналарның өчесе Карабанова Альмира, Клинкова Наилә, Солдатова Лариса үз балалары белән катнаштылар. Конкурслар берсеннән берсе кызыклырак иде: әниләр яңа туган баланы да төрүне дә искә төшерделәр, гаиләдә иң яраткан татар ашлары белән дә авыз иттерделәр, матуритеп җырладылар да. Ә балалары әниләренә иң матур, иң назлы сүзләр әйтә белүләрен күрсәттеләр, табышмакларның җавапларын тиз арада таптылар. Конкурсның җиңүчесе Карабанова Альмира булса да, ләкин һәр ана үз титулын яулады: Карабанова Гүзәл — «иң шәфкатьле ханым», Конькова Наилә — «иң чибәр ханым» титулларына лаек булдылар. Әниләрнең берсе дә бүләксез калмады. Бүләкләр өчен спонсорларга — Барсуков Ильдар Нәим улы һәм Курмакаев Руслан Фатых улына — бик зур рәхмәтләрен белдерделәр.

Авылым тавышлары

Хадисләр

«Җәннәттә шундый гүзәл йортләр бар ки, эче тышына, тышы эченә күренеп тора. Алар мөләем сүзле, кунакчыл кешеләр һәм башкалар йокладан вакытта төннәрдә намаз укучылар өчен хәзерләнеп куелалар».

«Кем ки Аллаһы хозурына тәкъва хәлендә барса, Ул аңа Исламдагы һәммә әҗер сәвапны бирер».

«Кешеләр белән берләшүче һәм кешеләр дә аның белән берләшүче кеше чын мөэмин була, әмма кешеләр белән берләшмәүче һәм кешеләр дә аның белән берләшмәүче кешедә һич яхшылык булмас. Кешеләрнең иң яхшысы — башка кешеләргә файдасы тигәне».

Халык авыз иҗаты

Мишәр фольклоры хәзинәсеннән (Ләмберә татар мәдәни үзәгенең директоры А.А. Максимова башкаруында тыңладык)

«КЫЗ БАЛА»

Әй, кыз бала, кыз бала,
Кыз бала — мескен бала!
Утка салсаң утта яна,
Суга салсаң — югала...

Кыз баланы үсеп җиткәч
Кадерләмә башлыйлар,
Роза чәчәге шикелле,
Йөзеп җиргә ташлыйлар.

Кыз баланың ятыр урыы —
Пич алдында бер такта.
Шул тактаны да, кызганып,
Аны бирәләр ятка.

Туса — тусын ир баласы
Ат өстендә уйнарга.
Тумасын мескен кыз бала,
«Бәхетем юк!» — дип, еларга.

Казанда регионара конференциясе үтте

27—29 октябрь көннәрендә Казан шәһәрендә регионара «Россияда этникара мөнәсәбәтләренең ярашлыгында милли—мәдәни автономияләренең әһәмиятлеге» дигән конференция үткәрелде.

Бу конференциягә илебезнең утыз регионнарыннан делегацияләр җыелды. Делегатлар арасында — безнең дә вәкилләре бар иде. Республикабызның татар милли—мәдәни «Якташлар» автономиясенең әгъзасы Шамиль Зәкәриә улы Бикмәев, Ләмберә районының татар милли мәдәни үзәгенең җитәкчесе Әльфиә Асым кызы Максимова һәм Ләмберә районы мәдәният бүлегенең белгече Мария Семен кызы Громова Мордовияне тәкъдим иттеләр. Конференция барышында Федераль милли мәдәни автономиянең киң утырышы узды. Бу утырышта регионнардан килгән делегатлар үзләренең милли үзәкләренең эш тәҗрибәсе белән уртаклаштылар, Дуслык йортлары турында сөйләделәр, милли сорауларга җаваплар эзләделәр, этникара мөнәсәбәтләр мәсьәләрен чишү юлларын табырга һәм башка нәрсәләрне тикшерделәр. Беренче көнне төрле җирләрдән җыелган вәкилләрне кунак иттеп каршыладылар һәм алар өчен Казан шәһәре буенда бик кызыклы, мавыктыргыч экскурсиядә йөрттеләр. Казан Кремленә кергездәләр. Икенче көнне конференциянең ачылуы һәм пленар утырышы узды. Шул ук көнне конференциянең төп сессияләре үтте. «Этникара мөнәсәбәтләр һәм дәүләт милли сәясәте», «Милли—мәдәни автономияләр һәм башка иҗтимагый оешмалар бүгенге россиянең милли сәясәтендә» исемле җыелышларда бик әһәмиятле мәсьәләр чиштеләр.

Битне оештырды Умида Баймашева.